РЕСПУБЛИКА
ТАТАРСТАН

СОВЕТ ИЗМИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
САБИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

422052, Республика Татарстан, Сабинский район,
с.Измя, ул. Школьная, 9
тел. (84362) 49-1-32, (84362) 49-1-22

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫ

САБА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ ЭЗМӘ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

422052, Татарстан Республикасы, Саба районы,
Эзмә авылы, Мәктәп урамы, 9 йорт
тел. (84362) 49-1-32, (84362) 49-1-22

e-mail: lsm.sab@tatar.ru

РЕШЕНИЕ
04.06.2021

КАРАР
№15

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы
Эзмә авыл җирлеге Советының 14.03.2013 елгы
12 номерлы карары белән расланган Эзмә авыл
җирлегендә гражданнар тарафыннан хосусыйлаштырылган
торак биналарны муниципаль милеккә тапшыру тәртибе
турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына ана (гаилә) капиталы акчаларын куллануга бәйле мәсьәләләр буенча үзгәрешләр кертү турында» гы Федераль законга үзгәрешләр кертү турында»гы 35-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Эзмә авыл җирлеге Советы

КАРАР КЫЛДЫ:

1. Саба муниципаль районы Эзмә авыл җирлеге Советының 14.03.2013 елгы 12 номерлы «Гражданнар тарафыннан хосусыйлаштырылган торак биналарны Эзмә авыл җирлегенә муниципаль милеккә тапшыру тәртибе турында" гы карары белән расланган Эзмә авыл җирлеге Советы тарафыннан хосусыйлаштырылган торак биналарны гражданнар тарафыннан муниципаль милеккә тапшыру тәртибе турындагы Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. 2.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.1. Хосусыйлаштырылган торак урыннарны Эзмә авыл җирлеге муниципаль милкенә тапшырырга теләгән гражданнар, Эзмә авыл җирлеге Башкарма комитетына торак урынының барлык милекчеләре тарафыннан имзаланган, гражданның шәхесен таныклаучы документның төп нөсхәсен күрсәтеп, Эзмә авыл җирлеге Башкарма комитеты җитәкчесе исеменә гариза тапшыралар. Гаризага муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты белән билгеләнә торган документлар теркәлә.».

2. Әлеге карарны "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Эзмә авыл җирлегенең рәсми сайтында: http://saby.tatarstan.ru/rus/izma адресы буенча һәм җирлекнең мәгълүмати стендларында бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Эзмә авыл
җирлеге башлыгы                                                   А.Р.Шәйхетдинов